Муниципаль тур

Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ
2023-2024 нче уку елы
11 нче сыйныф

ВАРИАНТ 1

Максималь балл – 61

I. ТЕСТ (20 балл)

1	2	3	4	5	6	7	8	9	10
2	**4**	**1**	**2**	**3**	**3**	**2**	**1**	беркөнне	Ике нокта

II. Теоретик бирем.

Иярченле кушма җөмлә турында языгыз, мисаллар китерегез. (**6 балл**)

Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Мәкаль һәм андагы хайван атамасын тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

А) Авыр йөкне... тартыр.	1) кәҗә
Ә) Кемгә нәрсә, ... - кәбестә.	2) тычкан
Б) Араларыннан кара ... үткән.	3) үгез
В) Койрыгына бассаң, ... дә чыелдый.	4) мәче
Г) .... мөгезеннән эләктер.	5) ат

Җавап : **51423**

IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(5 балл)**

Татар халкының күңелле бәйрәмнәре, бай гореф-гадәтләре һәм йолалары бар. Мәсәлән, ел (вакытына / **фасылларына** / чорына) бәйле Сабантуй һәм Нәүрүз бәйрәмнәре үткәрелә, ислам диненә бәйле Корбан бәйрәме, йолаларга бәйле каз өмәсе (ачыклап / **билгеләп** / күрсәтеп) үтелә. Еллар (**үткән** /барган / аккан) саен, бу бәйрәмнәр яңара, аларның формалары үзгәрә һәм эчтәлекләре тулылана бара.

Хәзер каз өмәсе ничек оештырыла һәм үткәрелә соң?

Башка өмәләр үзенчәлекле булган кебек үк, каз өмәсен (барлау / **оештыру** / үткәрү) һәм уздыруның да үзенә генә хас тәртибе бар. Ул һәр елны көз ахырында яисә кыш башында үткәрелә.

Бүтән өмәләрдән аермалы буларак, каз өмәсе - башыннан азагына кадәр кызлар өмәсе. Казлары (чиксез / **күп** / гаять) кешеләр иртәгә өмә уздырыласы көнне кызларны чакырып чыгалар. *(Вакытлы матбугаттан)*

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Ак кәгазьдән каләм эзе тиз җуела,
Караны да, тушьларны да җуеп була.
Ташка язган сүзләрне дә еллар ала.
Күңелләргә язылган сүз мәңге кала.
Синең бурыч <....> күңелләргә сүзләр язу,
Язар өчен алтын сүзләр эзләп табу.
Әзер юлдан үз көеңә бару җиңел.
Тигез җирдә юл салу да авыр түгел. (*Э. Мөэминова*)

3. Шигырьнең икенче куплетындагы <....> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз. **(2 балл)**

сызык

4. *Язар өчен алтын сүзләр эзләп табу* җөмләсеннән күчерелмә мәгънәле сүзне күчереп языгыз. (**2 балл**)

Алтын сүзләр

5. Беренче куплеттан сыйфат фигыльләрне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**5 балл**)

Ташка язган, язылган, үткән заман сыйфат фигыльләр, барлыкта.

яз – тамыр, -ыл, -ган – модаль кушымчалар

6. Шигырьдән ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)**

өчен, көеңә

7. *Ташка язган сүзләрне дә еллар ала* җөмләсенә синтаксик анализ ясагыз.
(2 балл)

Еллар – гади ия, ала – гади хәбәр, ташка язган – аергыч, сүзләрне – туры тәмамлык. Бу-ике составлы җәенке, тулы, гади хикәя җөмлә.

8.“*Күңелгә язылган матур сүз*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)